РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«13» июля 2022г.

г. Альметьевск

№ 77

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 28 декабрендәге 60 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 27 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 21 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 28 декабрендәге 60 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2017 елның 30 мартындагы 74 номерлы, 2017 елның 05 маендагы 78 номерлы, 2017 елның 31 маендагы 83 номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 91 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 114 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 135 номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 146 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 192, 2020 елның 28 августындагы 209 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 12 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 53 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада:

а) 2 бүлекнең 2.5 пунктындагы җиденче абзацын «муниципаль хезмәт вазыйфасы» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль хокукый актларда муниципаль хезмәт вазыйфаларының елкән һәм (яисә) кече теркемнәре вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларына «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу кергән очракта (урта гомуми белем булган очракта) күрсәтелмәскә мөмкин.»;

б) 6 бүлекнең 6.5 пунктын «Муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр» тешереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.А.).

Шәһәр Башлыгы «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» Т. Д. Нагуманов